ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**29 декабрь 2023 ел** **№ 86**

**«Җир салымы турында» 2019 нчы елның 22 нче ноябрендәге 148 нче номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге советы Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Җир салымы турында» 2019 нчы елның 22 нче ноябрендәге 148 нче номерлы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы карарына (2020 нче елның 15 нче маендагы 164 нче номерлы, 2022 нче елның 25 нче ноябрендәге 57 нче номерлы, 2023 нче елның 13 нче ноябрендәге 78 нче номерлы Совет карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның 1 нче пунктчасының 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары (торак фондына карамаган һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);».

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының 2023 нче елның 13 нче ноябрендәге 78 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Җир салымы турында» 2019 нчые елның 22 нче ноябрендәге 148 нче номерлы Красносельский авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 нче статьясына ярашлы рәвештә законлы көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.